**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2023 елның 28 августы №42 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы район
Советының 26.10.2016 № 29 карары белән
расланган, Аукционнар үткәрмичә сатыла торган
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы муниципаль милкендә булган җир
кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе
турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү
хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып барулары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2016 елның 26 октябрендәге 29 нчы номерлы карары белән расланган, Торглар үткәрмичә генә сатыла торган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 нче номерлы Кушымтасының 3 пункты 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә, шәхси торак төзелеше, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык, дача хуҗалыгы, гражданнарга яки крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир участоклары.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм

җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин